МБМБУ «Арча 2 нче балалар бакчасы»

# ЧИШМӘ БАШЫ

№4, 01.12.2025 ел



# Ап-ак карлы кыш

Тәңкә карлар сибелгән
Җир ап-акка күмелгән.
Чыршы,каен,имән
Карданн чикмән кигән.
Бу кайчак?(кыш)

**Ява карлар, яңа карлар**…(Р.Миңнуллин)
Ява карлар, яңа карлар –
Кышның ак гөлләре.
Якты булсын, ап-ак булсын
Илемнең көннәре.
Ишетелеп торсын җирдә
Балалар көлгәне.
Ява карлар, яңа карлар,
Ак – гомер юллары,
Дәвам итсен гомер буе
Тынычлык еллары.
Яңгырасын җир өстендә
Тынычлык җырлары.

**Ак мизгел** ( Р.Миңнуллин )
Яратам мин ап-ак төсне
Бөтен дөнья ап-ак төсле.
Куяннар да ак тун кигән
Каеннар да ак туннан.
Бүреккә дә, керфеккә дә
Борынга да ак кунган.
Биек булып, ап-ак булып
Урамга ак кар яуган.
Көне буе шау-гөр килеп
Шуабыз шул ак таудан.

## Кыш турында сынамышлар:

- Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.
- Кышның төньяк бураннары ашлык җыйганда яңгыр китерер.
- Гыйнварның унында бәс төшсә, җәй яңгырлы килер.
- Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.
- Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.
- Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.
- Гыйнвар унында бәс тотса, җәй яңгырлы килә.
- Әгәр елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.
- Тоз юеш булса, кыш көне җепшек була.



Саф һавада уеннарны балалар бик ярата. Нинди генә һава торышы булмасын, урамда алар табигатьне күзәтә, хәрәкәтле уеннар уйнап чыныга.Балалар бакчасында кыш көне урамда уйнар өчен берничә уен тәкъдим итәбез.

***«Җиз бүкән»***
Балалар бер түгәрәктә, «җиз бүкән» булып, чүгеп утыралар. Һәрберсенең артында бер иптәше басып саклап тора. Арада бер бала бүкәнсез калдырылган була. Ул арттан килә дә «сакчы» белән сүз башлый:
– Җиз бүкән, җиз бүкән сатлык микән?
– Җиз бүкән сатлык икән.
– Күпме хак алыр икән?
– Хак ярым хак, пот ярым борчак икән.
– Әйдә, йөгерешеп карыйк, кем килеп алыр икән? – диләр дә түгәрәк тышыннан бер-берсенә каршы йөгереп әйләнәләр. Җиз бүкән иң элек әйләнеп килгәннеке була.



## Әйдәгез, бергәләп җырлыйк!

КЫШ БАБАЙ

Безнең чыршыбызны бизәп
Балкып кабына утлар
Яңа елның килүләрен
Хәбәр итә курантлар.
Кушымта:
Кыш бабай, Кыш бабай
Безне бик ярата.
Ул безгә Яңа ел
Бүләге тарата.
Ак чәчәк кебек кар ява
Урманнарга, кырларга
Тынычлык алып Яңа ел
Килсен бөтен дөньяга.

Кушымта:
Кыш бабай, Кыш бабай
Безне бик ярата.
Ул безгә Яңа ел
Бүләге тарата.



**Чыршы янында**

Ямь-яшел ылыслары,
Балкып тора утлары.
Чыршыкай,чыршыкай,
Бигрәк матур чыршыкай.
Сиңа килгән кунаклар-
Аюлар һәм куяннар.
Чыршыкай,чыршыкай,
Бигрәк матур чыршыкай.



## Әйдәгез, бергәләп укыйк!

Йолдызчыклар иле

Арча шәһәренең 2 номерлы балалар бакчасында «Йолдызчыклар» исемле бер төркем бар иде. Ул төркемдә шат күңелле, дус, ярдәмчел балалар йөри иде. Аларның тәрбиячеләре Ләйсән һәм Тәнзилә апалары һәр көнне яңа мавыктыргыч уеннар, кызыклы шөгыльләр уйлап таба.

Көннәрдән бер көнне бакчада гаҗәеп хәл булды: бүлмә почмагында тылсымлы сандык пәйда булды. Балалар ап-ак кар бөртекләре кебек, янәшә килеп җыелдылар. Сандык ачылып китте, аннан нур чәчеп бер төркем кечкенә йолдызчык очып чыкты.

Йолдызчыклар балаларга карап елмайды да болай диде:

— Без Күк иленнән килдек! Кем шушы бакчада иң тырыш, ярдәмчел һәм шәфкатьле икәнлеген белергә теләдек.

Балалар бергәләп уеннар уйнады, матур җырлар җырлады, шигырьләр сөйләде һәм бер-берсенә булышты. Гөлүсә бергәләп уенчыкларны җыештырды, Алсу дустына рәсем буярга ярдәм итте, Динар һәм Рамазан дусларына китфәш итте.

Көн ахырында йолдызчыклар кабат очып килеп әйтте:

— Сезнең төркем — чын йолдызлар иле! Чөнки бер-берегезгә ярдәм итәсез, дус яшәдегез, изгелек һәм матурлык тараттыгыз.

Шуннан соң һәр бала күңелендә кечкенә генә йолдыз кабынды. Ә 2 номерлы бакчадагы «Йолдызчыклар» төркеме дөньяда иң дустанә, нурлы һәм тату төркем булып калды.




## Балалар бакчасында Г.Тукайның 140 еллыгына багышланган күргәзмә.

*Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның 140 еллыгына безнең балалар бакчасында уза торган балалар эшләре күргәзмәсе багышланып китте. Күргәзмәдә төрле материаллардан ясалган рәсемнәрне һәм эшләнмәләрне күрергә мөмкин. Әсәрләрнең геройлары кәгазьдән, пластилиннан, пластиктан башкарылган иде. Мондый чаралар балалар бакчаларында да үткәрелә, балаларга иҗат күрсәтергә һәм шагыйрь иҗаты белән танышырга мөмкинлек бирә.*









Кайда кыш.

Кышның беренче көннәре,
Тик һаман яңгыр ява.
Кыш көнендә урамнарда,
Әле дә җылы һава.

Яңа ел бәйрәмнәренә,
Бары калды дүрт атна.
Әй кыш бабай,кыш бабай,
Яңа ел кары кайда.

Яңгыр явып тора көн дә,
Оныткан кыш җиткәнен.
Ак карларны,салкыннарны,
Инде күңел көткәнен.

Каршы түгел инде үзем,
Кабат җәйләр җитсә дә.
Кыш айлары карсыз гына,
Җылы гына үтсә дә.
1.12.2025
Халидә Асхадуллина

# Яңа елга әзерлек башланып китте

Иң яраткан һәм күптән көтелгән бәйрәм - Яңа ел якынлаша! Бу Яңа ел алдыннан безнең балалар бакчасында Яңа ел иртәләре һәм бәйрәмнәренә интенсив әзерлек бара. Кыш бабайга чын күңелдән ышанган халыкның бер өлешендә күтәренке кәеф тудыру буенча эш алып барыла.

Яңа елга балалар бакчасын бизәү - бер үк вакытта авыр һәм күңелле эш. Эш күп - төркемне, кабул итү бүлмәләрен, баскыч юлларын, музыка залын, урам территориясен якты һәм төсле декорацияләр белән бизәргә кирәк. Ә балалар бакчасында тәрбиячеләр уйлап табучы халык булганлыктан, Яңа елга да, кагыйдә буларак, дизайнерларның кыйммәтле хезмәтләренә мөрәҗәгать итмичә, барысын да үз көчләре белән бизиләр.

Ләкин төп әкияти бизәкләр балалар бакчасы төркемнәрендә урнашкан: яңа ел чыршылары, уенчыклар, эшләнмәләр, тәрәзәләрдә буяу белән ясалган яңа ел композицияләре күзгә ошый һәм төрле утлар белән ялтырап тора, ә стеналарда - ясалган гирляндалар, Кыш бабай һәм Кар кызы силуэтлары.













Кыш - елның иң тылсымлы, яраткан вакыты! Балалар аны түземсезлек белән көтәләр! Без кышкы очрашуга

Кыш - елның иң тылсымлы, яраткан вакыты! Балалар аны түземсезлек белән көтәләр! Без кышкы очрашуга әзерләнергә һәм балалар белән кышкы темага плакат ясарга булдык. Моның өчен безгә ватман кирәк иде, без аны матур итеп бизәдек, кышкы фон бирдек!Һәр бала кәгазьдән үз кошын ясады. Кошлар бик матур килеп чыкты. Балалар белән кышын кошларга ничек ярдәм итә алуыбыз турында сөйләштек. Балалар аларны май, орлык, кипкән җиләк белән тукландырырга кирәклеген әйттеләр. Барлык кышлаучы кошларны искә алдык! Безнен стена газетасы бик кызыклы һәм кышкы матур булып чыкты!




## Котлыйбыз!

Декабрь аенда үзләренең туган көннәрен билгеләп үтүче кадерле хезмәттәшләребез.

***Зарипова Ләйсән Рәҗәп кызын 14.12.1981***
***Мөхәмәтгәлиева Гөлназ Ильгиз кызын 19.12.1980***

*Ихлас йөрәктән гомер бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Туар таңнарыгыз ышанычлы, гомерләрегез – бәхетле, бәхетләрегез – гомерле булсын. Якыннарыгызга кирәк һәм терәк булып, кадер-хөрмәттә яшәгез. Сезгә озын гомер, ныклы саулык, куаныч, ак бәхетләр телибез.*

Йөрәкләрдән чыккан назлы сүзләр,
Күңелләрдә булган саф хисләр
Озын гомер, якты, тыныч тормыш –
Безнең сезгә әйтер теләкләр.

